# КАРАР
## Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Советы

Илбәк авылы №136 «01» август 2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Советының 08.12.2017 ел №73 «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Илбәк авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча аерым вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны кабул итү турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2015 ел 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Советының 25.03.2015 ел № 119/1 карары белән расланган, Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге җирле үзидарә органнары һәм Азнакай муниципаль районы җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турындагы килешүләр төзү тәртибе, Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 23.05.2019 ел, №262-32 «Азнакай район Советының 13.12.2017 ел кабул ителгән «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнарына җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында»гы карарын исәпкә алып

Илбәк авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Советының 08.12.2017 ел №73 «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Илбәк авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча аерым вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны кабул итү турында» карарына, 1 пуктны түбәндәге эчтәлекле 15 абзац белән тулыландырып, үзгәрешләр кертергә:

«-җирлектә яшәүче һәм аз керемле гражданнарны торак урыннары белән тәэмин итү, торак төзелеше өчен шартлар тудыру (муниципаль торак фондын төзүне оештыру һәм карап тоту, муниципаль торак контролен, шулай ук торак законнары нигезендә җирле үзидарә органнарының башка вәкаләтләрен гамәлгә ашырудан тыш).».

2. Илбәк авыл җирлеге Башкарма комитетына әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты белән өстәмә килешү төзергә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес: http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Азнакай муниципаль районының Интернет-мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: http//aznakayevo.tatar.ru. веб-адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Бюджет, салымнар, финанслар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Л.Р.Әсәдуллина